| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**КАВЗИЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО**<br>**ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **Татарстан Республикасы**<br>**САРМАН**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЭУЖИЯК**<br>**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА**<br>**КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

30 апрель 2025 ел — № 49

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләрен акчалата карау турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 14.04.2025 № 228 карары нигезендә«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында «Җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында», районның Кәүҗияк авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Кәүҗияк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата эчтәлеге турында» 2018 елның 10 августындагы 7 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарның 1 нче кушымтаның 2 пунктында «13 990» санын «15 389» саннарына алмаштырырга;
- карарның 3 нче кушымтаның 6 пунктында «41 процент» сүзләрен «59 процент» сүзләренә алмаштырырга;
- карарның 7 нче кушымтада «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә әлеге карарны игълан итәргә.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 майдан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сарман муниципаль районы
Кәүҗияк авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе — Ф. Ә. Хөснетдинов